ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл жирлеге башлыгы**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Глава Старотатарско-Адамского сельского поселения Аксубаевского муниципального района**

**423055 Республика Татарстан Аксубаевский район с. Старый Татарский Адам, ул. Центральная дом 20**

Тел. (8-84344-4-35-84) ОГРН 1021605359610,
ОКПО 27839564, ИНН/КПП 1603000965/160301001
E-mail: *Stadam.Aks@tatar.ru*

---

КАРАР

17 ноябре 2023 ел ел. № 4

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге
Иске Татар Әдәмсуы авылы
гражданнарының үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Иске Татар Адәмсуы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 27 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Иске Татар Әдәмсуы авылы Үзәк урамы, 17 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлегенең Иске Татар Әдәмсуы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, контракт буенча хезмәткәрләрне, волонтерларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергәләп яшәүче ата-аналар, ир белән хатыннар, балигъ булган балалар)түләүдән азат итүдән тыш, 500 сум күләмендә 2024 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1. 1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм тоту (Иске Татар Әдәмсуы торак пунктында вак таш сатып алу, вак таш салу буенча эшләрне башкару; юлларны кышкы тоту (килешү буенча түләү).
2. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын үткәрүне тәэмин итү:
янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу).
3. Күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:
- урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен килешү буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, Иске Татар Әдәмсуы авылы урамнарында энергия саклаучы лампалар сатып алу, сатып алу, урнаштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ruһәмхокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга:http://pravo.tatarstan.ru/

Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы авыл
җирлеге башлыгы: Э. М. Хөснуллина